ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27 март 2020ел № 1541

Яр Чаллы шәһәренең сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү муниципаль мәгариф оешмаларын финанслау нормативларын исәпләү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының балаларга сәнгать-эстетика юнәлешендә өстәмә белем бирүче мәгариф учреждениеләрен норматив буенча финанслауны кертү турында» 2009 елның 14 декабрендәге 854 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү муниципаль мәгариф оешмаларын финанслау нормативларын исәпләү тәртибен кушымтада каралганча расларга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы И.А. Сәгыйдуллинага, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 27 мартындагы
1541 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең
сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә
белем бирү муниципаль мәгариф оешмаларын
финанслау нормативларын исәпләү
тәртибе

1 бүлек. Гомуми нигезләмләр

1. Әлеге тәртип сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрендә өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга финанс чыгымнары нормативын, сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү учреждениесе мөлкәтен карап тоту нормативын һәм сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү учреждениесен финанс белән тәэмин итү күләмен исәпләү тәртибен билгели.

2. Әлеге тәртиптә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр файдаланыла:

1) сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрендә өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга финанс чыгымнары нормативы (алга таба – финанс чыгымнары нормативы) ул сәнгать-эстетика юнәлешендә - балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрендә билгеләнгән таләпләр нигезендә өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга кирәкле булган финанс чыгымнарының рөхсәт ителгән минималь күләме.

2) сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү учреждениесе мөлкәтен карап тоту нормативы ул (алга таба – мөлкәтне карап тоту нормативы) сәнгать-эстетика юнәлешендә - балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре бүлмәләрен җиһазлауга билгеләнгән таләпләр һәм биналарын эксплуатацияләүнең техник нормалары нигезендә өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга кирәк булган финанс чыгымнарының рөхсәт ителгән минималь күләме.

3. Финанс чыгымнары нормативлары һәм мөлкәтне карап тоту нормативлары ел саен Башкарма комитет карары белән билгеләнә.

4. Өстәмә белем бирү оешмасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең чыгым йөкләмәсе булып тора һәм шәһәр бюджеты акчалары хисабына финанслана.

5. Финанс чыгымнары нормативлары гамәлдә булу чоры дәвамында бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү буенча законнар нигезендә билгеләнгән Бердәм тариф челтәре хезмәт хакы ставкасының һәм (яки) беренче разрядлы тариф ставкасының (окладының) база өлеше үзгәрү белән бер үк вакытта вакытыннан алда яңадан каралырга тиеш.

6. Финанс чыгымнары нормативының һәм мөлкәтне карап тоту нормативының зурлыгы гражданнарга күрсәтелә торган бюджет белем бирү хезмәтенең гарантияләнгән минималь бәясе булып тора һәм чираттагы финанс елына һәм план чорына шәһәр бюджетын формалаштырганда мәҗбүри кулланылырга тиеш (алга таба –шәһәр бюджеты).

7. Финанс чыгымнары нормативы сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү учреждениесендә өстәмә белем бирү программасының юнәлешенә, әзерлек дәрәҗәсенә, укыту срокларына һәм дәрәҗәсенә карап дифференцияле билгеләнә.

8. Финанс чыгымнары нормативы елга бер укучыга исәбеннән билгеләнә. Мөлкәтне карап тоту нормативы айга җылытыла торган мәйданның бер квадрат метрына билгеләнә.

9. Әлеге тәртип белән балалар сәнгать мәктәпләренең, шул исәптән сәнгать төрләре буенча, финанс чыгымнарын исәпләү нормативлары һәм мөлкәтне карап тоту нормативлары регламентлана.

10. Балаларга өстәмә белем бирү программалары юнәлештән чыгып, түбәндәгечә дифференцияләнә:

1) музыка сәнгате;
2) рәсем сәнгате;
3) фольклор сәнгате;
4) хореография сәнгате;
5) эстрада-джаз сәнгате;
6) театр сәнгате;
7) гомуми эстетика сәнгате.

11. Балаларга өстәмә белем бирү программалары укыту дәрәҗәсеннән чыгып, түбәндәгечә дифференцияләнә:

1) иртә эстетика белеме бирү;
2) төп сәнгать-эстетика белеме бирү;
3) иртә һөнәри белем бирү.

12. Төп сәнгать-эстетика белеме бирү дәрәҗәсе ике баскычка бүленә: урта сыйныфлар һәм кече сыныфлар.

## 2 бүлек. Балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрендә өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга финанс чыгымнары нормативын исәпләү тәртибе

13. Балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрендә өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыру чыгымнарына балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләре укытучыларына хезмәт хакы түләү чыгымнары (педагогик, административ, укыту-ярдәмче персоналның хезмәт хакы тарифы һәм тарифтан тыш өлеше, хезмәт хакына өстәлгән сумма), дәреслекләргә һәм уку пособиеләренә, техник укыту чараларына, тотыла торган материалларга һәм хуҗалык ихтыяҗларына (биналарны карап тоту чыгымнары һәм коммуналь чыгымнардан тыш) чыгымнар керә.

14. Финанс чыгымнары нормативы бер тәрбияләнүчегә исәбеннән түбәндәгеләргә нигезләнеп билгеләнә:

1) педагогик хезмәт күрсәтүнең стандарт (база) бәясе;

2) педагогик хезмәткәрләрнең хезмәт хакы ставкаларының һәм административ-идарә һәм укыту-ярдәмче персоналның хезмәт хакы ставкаларының норматив нисбәте;

3) тариф фонды һәм өстәмә түләүләр фонды нисбәте;

4) белем бирү процессын тәэмин итү чыгымнары (дәреслекләр һәм уку пособиеләре, техник укыту чаралары, тотыла торган материаллар сатып алу чыгымнары, хуҗалык чыгымнары һ.б.);

5) административ-идарә һәм укыту-ярдәмче персонал эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары (тотыла торган материаллар, канцелярия товарлары сатып алу чыгымнары, хуҗалык чыгымнары һ.б.);

6) белгечләрнең окладларын һәм тариф ставкаларын 25 процентка күтәрүне билгели торган федераль законнар нормаларына өстәмә региональ законнар нормалары.

15. Педагогик хезмәт күрсәтүнең стандарт (база) бәясен исәпләү бер укучыга өстәмә белем бирү программаларының юнәлеше, әзерлек дәрәҗәсе һәм укыту сроклары буенча, түбәндәге күрсәткечләрдән чыгып, гамәлгә ашырыла:

1) уку вакытының бер укучыга атналык педагогик сәгатьләр саны, 1нче таблицада каралганча;

2) укыту-ярдәмче персоналның бер укучыга атналык сәгатьләр саны, 2 нче таблицада каралганча;

3) әзерлек дәрәҗәсеннән һәм өстәмә белем бирү программасының юнәлешеннән чыгып укыту сроклары, 3 нче таблицада каралганча;

4) педагогик персоналның хезмәт хакы ставкасы Бердәм тариф челтәренең уникенче разрядына туры килә;

5) укыту-ярдәмче персоналның хезмәт хакы ставкасы Бердәм тариф челтәренең унынчы разрядына туры килә.

1 нче таблица

Балаларга өстәмә белем бирү программалары буенча уку вакытының бер укучыга атналык педагогик сәгатьләр саны

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлешенең исеме | Балаларга югары дәрәҗәдәге өстәмә белем бирү программалары буенча уку вакытының бер укучыга атналык педагогик сәгатьләр саны | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | төп сәнгать-эстетика белеме бирү | | | | | | Иртә һөнәри ориен тация |
| | өч еллык уку срогы | дүрт еллык уку срогы | биш еллык уку срогы | | җиде еллык уку срогы | | |
| | өлкән сыйныфлар | өлкән сыйныфлар | кече сыйныфлар | өлкән сыйныфлар | кече сыйныфлар | өлкән сыйныфлар | |
| Музыка сәнгате | - | - | 2,55 | 2,68 | 2,72 | 2,83 | 4,18 |
| Рәсем сәнгате | - | 1,41 | - | - | 0,88 | 1,41 | 2,82 |
| Фольклор сәнгате | - | - | 2,31 | 2,46 | 2,19 | 2,46 | 3,77 |
| Хореография сәнгате | - | - | 2,15 | 2,30 | 1,53 | 2,30 | 6,60 |
| Эстрада-джаз сәнгате | 4,06 | - | 3,68 | 4,04 | - | - | 6,5 |
| Театр сәнгате | 1,83 | - | 1,45 | 1,87 | 1,48 | 2,03 | 3,00 |
| Гомуми эстетик үсеш | - | - | 0,93 | 1,05 | - | - | - |

2 нче таблица

Балаларга өстәмә белем бирү программалары буенча укыту-ярдәмче персоналның бер укучыга атналык сәгатьләр саны

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлешенең исеме | Балаларга югары дәрәҗәдәге өстәмә белем бирү программалары буенча укыту-ярдәмче персоналның бер укучыга атналык сәгатьләр саны | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | төп сәнгать-эстетика белеме бирү | | | | | | Иртә һөнәри ориентация |
| | өч еллык уку срогы | дүрт еллык уку срогы | биш еллык уку срогы | | җиде еллык уку срогы | | |
| | өлкән сыйныфлар | өлкән сыйныфлар | кече сыйныфлар | өлкән сыйныфлар | кече сыйныфлар | өлкән сыйныфлар | |
| Музыка сәнгате | - | - | 0,88 | 1,01 | 0,70 | 0,86 | 0,89 |
| Рәсем сәнгате | - | 0,39 | - | - | 0,23 | 0,39 | 0,78 |
| Фольклор сәнгате | - | - | 1,42 | 1,51 | 1,35 | 1,51 | 2,15 |
| Хореография сәнгате | - | - | 1,93 | 2,03 | 1,31 | 2,03 | 6,20 |
| Эстрада-джаз сәнгате | 1,87 | - | 1,73 | 1,86 | - | - | 2,76 |
| Театр сәнгате | 0,90 | - | 0,78 | 0,90 | 0,78 | 0,90 | 0,60 |
| Гомуми эстетик үсеш | - | - | 0,53 | 0,55 | - | - | - |

3 нче таблица

Балаларны өстәмә белем бирү учреждениесендә әзерлек дәрәҗәсеннән һәм өстәмә белем бирү программасының юнәлешеннән чыгып укыту сроклары

| Өстәмә белем бирү программасы юнәлешенең исеме | Балаларга югары дәрәҗәдәге өстәмә белем бирү программалары буенча укыту-ярдәмче персоналның бер укучыга атналык сәгатьләр саны | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | төп сәнгать-эстетика белеме бирү | | | | | | Иртә һөнәри ориентация |
| | өч еллык уку срогы | дүрт еллык уку срогы | биш еллык уку срогы | | җиде еллык уку срогы | | |
| | өлкән сыйныфлар | өлкән сыйныфлар | кече сыйныфлар | өлкән сыйныфлар | кече сыйныфлар | өлкән сыйныфлар | |
| Музыка сәнгате | - | - | 2 | 3 | 4 | 3 | 1 |
| Рәсем сәнгате | - | 4 | - | - | 3 | 4 | 1 |
| Фольклор сәнгате | - | - | 2 | 3 | 4 | 3 | 1 |
| Хореография сәнгате | - | - | 2 | 3 | 4 | 3 | 1 |
| Эстрада-джаз сәнгате | 3 | - | 2 | 3 | - | - | 1 |
| Театр сәнгате | 3 | - | 2 | 3 | 4 | 3 | 1 |
| гомуми эстетика үсеше | - | - | 2 | 3 | - | - | 1 |

16. Административ-идарә персоналының хезмәтенә түләүгә чыгымнар өлеше түбәндәге күләмдә билгеләнә:

1) сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү учреждениесенең музыка бүлеге педагогик хезмәткәрләренең һәм укыту-ярдәмче персоналның хезмәтенә түләү фондының 16 проценты;

2) сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү учреждениесенең рәсем сәнгате бүлеге педагогик хезмәткәрләренең һәм укыту-ярдәмче персоналның хезмәтенә түләү фондының 25 проценты;

3) сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү учреждениесенең фольклор сәнгате бүлеге педагогик хезмәткәрләренең һәм укыту-ярдәмче персоналның хезмәтенә түләү фондының 15 проценты;

4) сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү учреждениесенең хореография сәнгате бүлеге педагогик хезмәткәрләренең һәм укыту-ярдәмче персоналның хезмәтенә түләү фондының 17 проценты;

5) сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү учреждениесенең эстрада-джаз сәнгате бүлеге педагогик хезмәткәрләренең һәм укыту-ярдәмче персоналның хезмәтенә түләү фондының 10 проценты;

6) сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү учреждениесенең театр сәнгате бүлеге педагогик хезмәткәрләренең һәм укыту-ярдәмче персоналның хезмәтенә түләү фондының 22 проценты;

7) сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү учреждениесенең гомуми эстетик үсеш бүлеге педагогик хезмәткәрләренең һәм укыту-ярдәмче персоналның хезмәтенә түләү фондының 29 проценты.

17. Сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү учреждениесе педагогик хезмәткәрләренең һәм укыту-ярдәмче персоналның тарифтан тыш өстәмә түләүләр фонды педагогик хезмәткәрләрнең һәм укыту-ярдәмче персоналның хезмәтенә түләү тариф фондының 60 процентын тәшкил итә.

18. Белем бирү процессын тәэмин итү чыгымнары күрсәтмә пособиеләр, укыту чаралары, укыту-методик әдәбият, мәгълүмати-коммуникатив чаралар, экранлы-тавышлы пособиеләр, тотыла торган материаллар, канцелярия товарлары сатып алу чыгымнарын, шулай ук командировка чыгымнарын һәм педагогик хезмәткәрләргә методик әдәбият сатып алу өчен компенсация түләүләрен үз эченә ала.

19. Белем бирү процессын тәэмин итү чыгымнары түбәндәгеләрдән тора:

1) сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү учреждениесенең музыка бүлеге, фольклор бүлеге, эстрада-джаз бүлеге педагогик хезмәткәрләренең һәм укыту-ярдәмче персоналның хезмәтенә түләү фондының 12 проценты;

2) сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү учреждениесенең рәсем сәнгате бүлеге педагогик хезмәткәрләренең һәм укыту-ярдәмче персоналның хезмәтенә түләү фондының 20 проценты;

3) сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү учреждениесенең хореография сәнгате бүлеге, театр сәнгате бүлеге педагогик хезмәткәрләренең һәм укыту-ярдәмче персоналның хезмәтенә түләү фондының 18 проценты;

4) сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү учреждениесенең гомуми эстетик үсеш бүлеге педагогик хезмәткәрләренең һәм укыту-ярдәмче персоналның хезмәтенә түләү фондының 17 проценты.

20. Сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү учреждениесенең административ-идарә персоналы эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары (тотыла торган материаллар, канцелярия товарлары сатып алу чыгымнары, хуҗалык чыгымнары һ.б.) административ-идарә персоналы хезмәтенә түләү фондының 10 процентын тәшкил итә.

21. Финанс чыгымнар нормативы бер укучыга исәбеннән түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$N^{t}_{spd} = FOT^{t}_{spd} + MTO_{spd},$$

монда:

$N^{t}_{spd}$ - финанс чыгымнар нормативы;

$FOT^{t}_{spd}$ - педагогик персонал, административ-идарә һәм укыту - ярдәмчел персонал хезмәтенә түләү фонды, педагогик, административ-идарә һәм укыту - ярдәмчел персонал хезмәтенә түләү фондына өстәп исәпләнгән сумма белән;

$MTO_{spd}$ - белем бирү процессын һәм административ-идарә персоналы эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары;

s - балаларга өстәмә белем бирү программасының юнәлеше;

p - укыту дәрәҗәсе;

d - укыту срогы;

t - балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениесенең территориаль урнашу урыны.

22. Педагогик, административ-идарә һәм укыту- ярдәмчел персонал хезмәтенә түләү фонды педагогик, административ-идарә һәм укыту - ярдәмчел персонал хезмәтенә түләү фондына өстәп исәпләнгән суммалар белән түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$FOT^{t}_{spd} = FOT^{t}_{spd\,nc} + FOT^{t}_{spd\,yv} + FOT^{t}_{spd\,ayn},$$

монда:

$FOT^{t}_{spd\,nc}$ - педагогик персонал хезмәтенә түләү фонды, педагогик персонал хезмәтенә түләү фондына өстәп исәпләнгән суммалар белән;

$FOT^{t}_{spd\,yv}$ - укыту - ярдәмче персонал хезмәтенә түләү фонды, укыту - ярдәмче персонал хезмәтенә түләү фондына өстәп исәпләнгән суммалар белән;

$FOT^{t}_{spd\,ayn}$ - административ-идарә персоналы хезмәтенә түләү фонды, административ-идарә персоналы хезмәтенә түләү фондына өстәп исәпләнгән суммалар белән.

Педагогик персонал хезмәтенә түләү фонды педагогик персонал хезмәтенә түләү фондына өстәп исәпләнгән сумма белән түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$FOT^{t}_{spd\,nc} = \frac{\sum_{f=1}^{m} (a_{spdf\,nc} - z_{f\,nc} \times n_{f\,nc})}{y} \times b_{nc} \times e \times k_{s} \times 12,$$

монда:

$a_{spdf\,nc}$ - балаларга өстәмә белем бирү программасының юнәлеше, укыту баскычы, срогы һәм дәрәҗәсеннән чыгып, бер укучыга уку вакытының атналык педагогик сәгатьләр саны, 1 нче таблицада каралганча;

$z_{f\,nc}$ - укыту баскычыннан чыгып, педагогларның хезмәт хакы ставкасы өчен

сәгатьләр саны (24 сәгать - төп өстәмә белем бирү программасының беренче укыту баскычы өчен, 18 сәгать - төп өстәмә белем бирү программасының һәм иртә һөнәри белем бирү өстәмә белем бирү программасының беренче укыту баскычы өчен);

$n_f$ - төп дәрәҗә баскычында яки иртә һөнәри белем бирү дәрәҗәсендә өстәмә белем бирү учреждениесендә укыту срогы, 3 нче таблица нигезендә кабул ителгәнчә;

y - тиешле дәрәҗәдә өстәмә белем бирү программасы буенча укыту срогы;

m - өстәмә белем бирү программасы буенча укыту дәрәҗәсендә укыту баскычлары саны;

f - өстәмә белем бирү программасы буенча укыту дәрәҗәсендә укыту баскычының исеме;

$b_{nc}$ - хезмәт хакы ставкасы, әлеге нигезләмәнең 15 пункты нигезендә кабул ителгәнчә;

e - бердәм социаль салым буенча чигерүләр коэффициенты (1,262);

$k_s$ - педагогик хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләүнең тарифтан тыш фонды коэффициенты, әлеге нигезләмәнең 17 пункты нигезендә кабул ителгәнчә;

12 - елдагы айлар саны.

Укыту-ярдәмче персонал хезмәтенә түләү фонды укыту-ярдәмче персонал хезмәтенә түләү фондына өстәп исәпләнгән сумма белән түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$FOT^{t}_{spd\,yv} = \frac{\sum_{f=1}^{m} (a_{spdf\,yv} \times n_f)}{y} \times z_{yv} \times b_{yv} \times e \times k_{yv} \times 12,$$

монда:

$a_{sdpf\,yv}$ - уку вакытының атналык педагогик сәгатьләр саны, укыту-ярдәмче

персоналның, бер укучыга, балаларга өстәмә белем бирү программасының юнәлеше, укыту баскычы, срогы һәм дәрәҗәсеннән чыгып, 2 нче таблицада каралганча;

$z_{yv}$ – укыту-ярдәмче персоналның хезмәт хакы ставкасы өчен сәгатьләр саны (24 сәгать);

$n_{f}$ - төп һәм иртә һөнәри белем бирү программасы дәрәҗәсендәге баскычта өстәмә белем бирү учреждениесендә укыту срогы, 3 нче таблица нигезендә кабул ителгәнчә;

y - тиешле дәрәҗәдә өстәмә белем бирү программасы буенча укыту срогы;

m - өстәмә белем бирү программасы буенча укыту дәрәҗәсендә укыту баскычлары саны;

$b_{yv}$ - укыту-ярдәмче персоналның хезмәт хакы ставкасы, әлеге нигезләмәнең 15 пункты нигезендә кабул ителгәнчә;

e - бердәм социаль салым буенча чигерүләр коэффициенты (1,262);

$k_{yv}$ - укыту-ярдәмче персоналның хезмәткә түләү тарифтан тыш фонды коэфициенты, әлеге нигезләмәнең 17 пункты нигезендә кабул ителгәнчә;

12 - елдагы айлар саны.

Административ-идарә персоналы хезмәтенә түләү фонды административ-идарә персоналы хезмәтенә түләү фондына өстәп исәпләнгән сумма белән түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$FOT^{t}_{spd_{ayn}} = (FOT^{t}_{spd_{nc}} + FOT^{t}_{spd_{yv}}) \times l,$$

монда

l - педагогик хезмәткәрләрнең һәм укыту-ярдәмче персонал хезмәтенә түләү фонды һәм административ-идарә персоналы хезмәтенә түләү фонды нисбәте коэффициенты, әлеге нигезләмәнең 16 пункты нигезендә кабул ителгәнчә.

23. Белем бирү процессын һәм административ-идарә персоналы эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары түбәндәге формула белән исәпләп чыгарыла:

$$MTO_{sdp} = (FOT^{g}_{sdp\ nc} + FOT^{g}_{sdp\ yv}) \times v_{nc} + FOT^{g}_{sdp\ ayn} \times {}_{ayn} ,$$

монда:

$FOT^{g}_{sdp}$ - шәһәр җирлегендә педагогик персонал хезмәтенә түләү фонды, педагогик персонал хезмәтенә түләү фондына өстәп исәпләнгән сумма белән;

$FOT^{g}_{spd\ yv}$ - шәһәр җирлегендә укыту - ярдәмче персонал хезмәтенә түләү фонды укыту - ярдәмче персонал хезмәтенә түләү фондына өстәп исәпләнгән сумма белән;

$FOT^{g}_{spd\ ayn}$ - шәһәр җирлегендә административ-идарә персонал хезмәтенә түләү фонды административ-идарә персонал хезмәтенә түләү фондына өстәп исәпләнгән сумма белән;

$v_{nc}$ - белем бирү процессы чыгымнары һәм педагогик һәм укыту-ярдәмче персонал хезмәтенә түләү фондына өстәп исәпләнгән сумма белән педагогик һәм укыту-ярдәмче персонал хезмәтенә түләү фонды нисбәте коэффициенты, әлеге нигезләмәнең 19 пункты нигезендә кабул ителгәнчә;

$v_{ayn}$ - белем бирү процессы чыгымнары һәм административ-идарә персоналы хезмәтенә түләү фондына өстәп исәпләнгән сумма белән административ-идарә персоналы хезмәтенә түләү фонды нисбәте коэффициенты, әлеге нигезләмәнең 20 пункты нигезендә кабул ителгәнчә.

## 3 бүлек. Балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учрежденияләренең мөлкәтен карап тоту нормативын исәпләү тәртибе

24. Балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учрежденияләренең мөлкәтен карап тотуның база чыгымнарына түбәндәгеләр керә:

1) коммуналь хезмәтләр өчен түләү чыгымнары (су белән тәэмин итү, су бирү, җылылык белән тәэмин итү, электр белән тәэмин итү, каты көнкүреш калдыкларын чыгару һәм утильләштерү);

2) биналарны һәм корылмаларны агымдагы карап тоту һәм ремонтлау чыгымнары;

3) биналарны һәм корылмаларны капиталь ремонтлау чыгымнары;

4) аеруча кыйммәтле күчемле милекне карап тоту һәм ремонтлау чыгымнары;

5) аеруча кыйммәтле күчемле милек сатып алу чыгымнары.

25. Балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учрежденияләренең мөлкәтен карап тотуның база нормативы түбәндәгеләр нигезендә билгеләнә:

1) коммуналь хезмәтләргә чыгымнар нормативлары;

2) биналарны һәм корылмаларны агымдагы карап тоту һәм ремонтлау чыгымнары нормативы;

3) балаларга өстәмә белем бирү учреждениесе биналарының һәм корылмаларының бер кв. метрын торгызу бәясе;

4) биналарны һәм корылмаларны капиталь ремонтлауга чигерүләр нормативы;

5) белем бирү процессын оештыру өчен кирәк булган күчемле милекне яңарту бәясе;

6) күчемле милекне агымдагы карап тотуга һәм ремонтлауга чигерүләр нормативы;

7) күчемле милекне яңартуга чигерүләр нормативы.

26. Коммуналь хезмәтләр чыгымнарының зурлыгы елга бер укучыга түбәндәге күрсәткечләрдән чыгып исәпләнә:

1) коммуналь хезмәтләргә Татарстан Республикасы буенча минималь тарифлар;

2) мәйдан белән тәэмин ителү бер укучыга (3 кв. метр);

3) коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативлары, 4 нче таблицада каралганча.

4 нче таблица.

Балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениесендә коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативлары

| Коммуналь хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Файдалану нормативы |
|---|---|---|
| Су белән тәэмин итү | куб. метр/ук. елга | 1,20 |
| Су бүлү | куб. метр/ук. елга | 1,14 |
| Җылылык белән тәэмин итү | Гкал/кв. метр елга | 0,2138 |
| Кайнар су белән тәэмин итү | Гкал/ук. елга | 0,02087 |
| Электр белән тәэмин итү | кВт. сәг/ук. елга | 52,00 |
| Каты көнкүреш калдыкларын чыгару һәм утильләштерү | куб. метр/ук. елга | 0,15 |

27. Биналарны һәм корылмаларны агымдагы карап тотуга һәм ремонтлауга чыгымнар зурлыгы бер укучыга түбәндәге күрсәткечләрдән чыгып исәпләнә:

1) бер укучыга мәйдан белән тәэмин ителү, әлеге нигезләмәнең 26 пункты нигезендә;

2) биналарны һәм корылмаларны агымдагы карап тоту һәм ремонтлау бәясе нормативы, социаль өлкә учреждениеләрен агымдагы карап тоту һәм ремонтлау стандартлары нигезендә.

28. Балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениесе биналарының һәм корылмаларының 1 кв. метрын торгызу бәясе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән 2001 елгы смета бәяләре дәрәҗәсенә карата төзелеш-монтаж эшләре бәясенең индексына төзәтмәләр кертелгән 2001 ел бәяләрендә капитал салулар күләмен билгеләү һәм инвестор программаларын формалаштыру өчен, Татарстан Республикасы территориясендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләре объектларын төзү бәясенең зурайтылган күрсәткечләренә туры килә.

29. Биналарны һәм корылмаларны капиталь ремонтлауга чигерүләр нормативы СССР Министрлар Советының «СССР халык хуҗалыгының төп фондларын тулы яңартуга амортизация чигерүләренең бердәм нормалары турында» 1990 елның 22 октябрендәге 1072 номерлы карары белән расланган төп фондларны тулы яңартуга амортизация чигерүләренең нормасына тигез итеп кабул ителә, минималь стандартка җиткерүнең төзәтмәләр коэффициенты белән 1 процент күләмендә.

30. Балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрендә белем бирү процессын тәэмин итү өчен таләп ителә торган күчемле милекне торгызу бәясе, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрендә укыту шатларына карата гигиена таләпләренә туры килә торган балаларга өстәмә белем бирү учреждениесенең тиешле күчемле милек исемлегенә уртача базар бәяләре буенча билгеләнә.

31. Күчемле милекне агымдагы карап тотуга һәм ремонтлауга чигерүләр нормативы Россия Федерациясе мәгариф министрлыгының «Халык мәгарифе учреждениеләрен хуҗалык итүнең яңа шартларына күчерү буенча бер балага, тәрбияләнүчегә, укучыга исәбеннән тиешле иҗтимагый чыгымнар рекомендацияләре» 1990 елның 14 июнендәге

15113-Н номерлы приказы нигезендә балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрендә белем бирү процессын тәэмин итү өчен таләп ителә торган, әлеге нигезләмәнең 30 пункты нигезендә исәпләп чыгарылган күчемле милекне яңарту бәясенең 4 проценты күләмендә кабул ителә, аны минималь стандартка җиткерүнең төзәтмәләр коэффициенты белән.

32. Күчемле милекне яңартуга чигерүләр нормативы СССР Министрлар Советының «СССР халык хуҗалыгының төп фондларын тулы яңартуга амортизация чигерүләренең бердәм нормалары турында» 1990 елның 22 октябрендәге 1072 номерлы карары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрендә белем бирү процессын тәэмин итү өчен таләп ителә торган, әлеге нигезләмәнең 30 пункты нигезендә исәпләп чыгарылган күчемле милекне яңарту бәясенең 10 проценты күләмендә кабул ителә, аны минималь стандартка җиткерүнең төзәтмәләр коэффициенты белән.

33. Балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениесе мөлкәтен карап тотуга база нормативы түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$BNSI = \frac{K + S + B + F + M}{Sg \times 12},$$

монда:

BNSI - балаларга өстәмә белем бирү учреждениесе мөлкәтен карап тотуга база нормативы;

K - коммуналь хезмәтләргә чыгымнар күләме;

S - биналарны һәм корылмаларны агымдагы карап тоту һәм ремонтлау чыгымнарының күләме;

B - биналарны һәм корылмаларны капиталь ремонтлауга чигерүләр күләме;

F - күчемле милекне агымдагы карап тоту һәм ремонтлау чыгымнарының күләме;

M - күчемле милекне яңарту чыгымнары күләме;

Sq - бер укучыга мәйдан белән тәэмин ителү нормативы, әлеге нигезләмәнең 26 пункты нигезендә;

12 - елдагы айлар саны.

34. Коммуналь хезмәтләргә чыгымнар күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$K = P_{q} + P_{cw} + P_{hw} + P_{can} + P_{el} + P_{lit},$$

монда:

$P_q$ - җылыту өчен түләү күләме;

$P_{cw}$ - салкын су белән тәэмин итү өчен түләү күләме;

$P_{hw}$ - кайнар су белән тәэмин итү өчен түләү күләме;

$P_{can}$ - су бүлү өчен түләү күләме;

$P_{el}$ - электр белән тәэмин итү өчен түләү күләме;

$P_{lit}$ - каты көнкүреш калдыкларын чыгару һәм утильләштерү өчен түләү күләме.

Балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениесендә җылыту өчен түләү күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$P_g = Sq \times N_g \times T_{q_{min}},$$

монда:

$N_g$ - җылылык энергиясен куллану нормативЫ, 4 таблицада каралганча;

$T_{q_{min}}$ - җылылык энергиясенә Татарстан Республикасы буенча закон нигезендә билгеләнгән минималь тариф.

Салкын су белән тәэмин итү, кайнар су белән тәэмин итү, каты көнкүреш калдыкларын чыгару һәм утильләштерү өчен түләү күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$P_{cw,hw,can,el,lit} = N_{cw,hw,can,el,lit} \times T_{cw,hw,can,el,lit_{min}},$$

монда:

$N_{cw,hw,can,el,lit}$ - салкын су,

кайнар су белән тәэмин иту, су бүлү,электр белән тәэмин иту, каты көнкүреш калдыкларын чыгару һәм утильләштерү нормативы, 4 таблицада каралганча;

$T_{cw,hw,can,el,lit_{min}}$ - Татарстан Республикасы буенча закон нигезендә билгеләнгән минималь тариф салкын су белән тәэмин итүгә, кайнар су белән тәэмин итүгә ,су бүлүгә,электр белән тәэмин итүгә, каты көнкүреш калдыкларын чыгаруга һәм утильләштерүгә.

35. Биналарны һәм корылмаларны агымдагы карап тоту һәм ремонтлау чыгымнары зурлыгы түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$S = Sq \times T_{hs} ,$$

монда $T_{hs}$ - биналарны һәм корылмаларны агымдагы карап тоту һәм ремонтлау бәясе нормативы

36. Биналарны һәм корылмаларны капиталь ремонтлауга чигерүләр зурлыгы түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$B = Sq \times C_{bd_v} \times N_{cr} \times k_{b_{min}} ,$$

монда:

$C_{bd_v}$ - балаларга өстәмә белем бирү учреждениесе биналарының һәм корылмаларының 1 кв. метрын торгызу бәясе, әлеге нигезләмәнең 28 пункты нигезендә кабул ителгәнчә;

$N_{cr}$ - биналарны һәм корылмаларны капиталь ремонтлауга чигерүләр нормативы, әлеге нигезләмәнең 29 пункты нигезендә кабул ителгәнчә;

$k_{b_{min}}$ - минималь стандартка җиткерүнең төзәтмәләр коэффициенты

(0,6).

37. Күчемле милекне агымдагы карап тоту һәм ремонтлау чыгымнарының зурлыгы түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$F = \frac{C_{eq} \times N_{feq}}{m_{proekt}} \times k_{feq_{min}},$$

монда:

$C_{eq}$ - күчемле милекне торгызу бәясе балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрендә белем бирү процессын тәэмин итү өчен, әлеге нигезләмәнең 30 пункты нигезендә кабул ителгәнчә;

$N_{feq}$ - күчемле милекне агымдагы карап тотуга һәм ремонтлауга чигерүләр нормативы, әлеге нигезләмәнең 31 пункты нигезендә кабул ителгән;

$m_{proekt}$ - балаларга өстәмә белем бирү учреждениесенең проект егәрлеге (укучылар саны);

$k_{feq_{min}}$ - минималь стандартка җиткерүнең төзәтмәләр коэффициенты(0,2).

38. Күчемле милекне яңарту чыгымнары зурлыгы түбәндәге формула буенча исәплап чыгарыла:

$$M = \frac{C_{eq} \times N_{eeq}}{m_{proekt}} \times k_{eeq_{min}},$$

монда:

$N_{eeq}$ - күчемле милекне яңартуга чигерүләр нормативы, әлеге нигезләмәнең 32 пункты нигезендә кабул ителгәнчә;

$k_{eeq}$ - минималь стандартка житкерүнең төзәтмәләр коэффициенты 0,2).

39. Мөлкәтне карап тотуның база нормативына төзәтмәләр коэффициенты балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениесе территориаль дислокациясенең коммуналь хезмәт күрсәтүләр бәясенә (төзекләндерү дәрәҗәсе һәм жылылык энергиясенә, су белән тәэмин итүгә, су бирүгә, каты көнкүреш калдыкларын чыгару һәм утильләштерүгә тарифлар), балаларга өстәмә белем бирү учреждениесенең бер укучыга исәпләнгән мәйдан белән фактта тәэмин ителүенә, салым түләүләренә йогынты ясый торган дифференцияләнгән характеристикаларын исәпкә алырга мөмкинлек бирә һәм түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$KNSI_i = NSI_i : BNSI,$$

монда:

$KNSI_i$ - балаларга өстәмә белем бирү учреждениесе мөлкәтен карап тотуның база нормативына төзәтмәләр коэффициенты;

$NSI_i$ - балаларга өстәмә белем бирү учреждениесе мөлкәтен карап тоту нормативы.

40. Балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениесенең мөлкәтен карап тотуның нормативы, балаларга өстәмә белем бирү учреждениесе биналарының һәм корылмаларының айга жылытыла торган 1 кв. метр мәйданына исәбеннән, балаларга өстәмә белем бирүче һәрбер учреждение буенча дифференцияле, аның территориаль дислокациясен исәпкә алып, түбәндәге күрсәткечләр нигезендә билгеләнә:

1) коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә закон нигезендә билгеләнгән гамәлдәге тарифлар буенча билгеләнә торган коммуналь хезмәтләр күрсәтү чыгымнары;

2) балаларга өстәмә белем бирү учреждениесендә бер укучыга фактта мәйдан белән тәэмин ителү;

3) балаларга өстәмә белем бирү учреждениесендә уку процессын оештыру өчен таләп ителә торган мөлкәт салым салу объекты дип таныла торган салым чигерүләре, шул исәптән жир салымнары.

41. Балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениесенең мөлкәтен карап тоту нормативы түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$NSI_{iv} = \frac{K_i \times m_i + (S_i + B_i + F + M) \times m_i + Nl_i}{So_i \times 12},$$

монда:

$K_i$ - балаларга өстәмә белем бирү учреждениесенең коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итүчеләрнең законнар нигезендә билгеләнгән тарифлары буенча коммуналь хезмәтләр чыгымнарының төзәтмәләр кертелгән зурлыгы;

$S_i$ - бер укучыга фактта мәйдан белән тәэмин ителүне исәпкә ала торган, биналарны һәм корылмаларны агымдагы карап тоту һәм ремонтлау чыгымнарының төзәтмәләр кертелгән зурлыгы;

$B_i$ - бер укучыга фактта мәйдан белән тәэмин ителүне исәпкә ала торган, биналарны һәм корылмаларны капиталь ремонтлауга чигерүләрнең төзәтмәләр кертелгән зурлыгы;

$Nl_i$ - балаларга өстәмә белем бирү учреждениесендә уку процессын оештыру өчен таләп ителә торган мөлкәт салым салу объекты дип таныла торган салым чигерүләре зурлыгы, шул исәптән җир салымнары;

$m_i$ - балаларга өстәмә белем бирү учреждениесендә тәрбияләнүчеләр саны;

$So_i$ - балаларга өстәмә белем бирү учреждениесенең җылытыла торган гомуми мәйданы;

12 - елдагы айлар саны.

42. Коммуналь хезмәтләргә чыгымнарның төзәтелә торган зурлыгы түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$K_i = P_{iq} + P_{icw} + P_{ihw} + P_{ican} + P_{iel} + P_{ilit},$$

монда:

$P_{iq}$ - җылыту өчен түләүнең төзәтелә торган зурлыгы;

$P_{icw}$ - салкын су белән тәэмин итү өчен түләүнең төзәтелә торган зурлыгы;

$P_{ihw}$ - кайнар су белән тәэмин итү өчен түләүнең төзәтелә торган зурлыгы;

$P_{ican}$ - су бүлү өчен түләүнең төзәтелә торган зурлыгы;

$P_{iel}$ - электр белән тәэмин итү өчен түләүнең төзәтелә торган зурлыгы;

$P_{ilit}$ - каты көнкүреш калдыкларын чыгару һәм утильләштерү өчен түләүнең төзәтелә торган зурлыгы.

43. Балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениесендә җылыту өчен түләүнең төзәтелә торган күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$P^{t}_{iqv} = 0,98 \times \frac{V_{ih}}{So_i} \times q_o \times (16 - t_{med}) \times 10^{-6} \times T \times 24 \times T_{iq} \times S_q,$$

монда:

0,98 - Татарстан Республикасы шартлары өчен билгеләнгән төзәтмәләр коэффициенты;

$V_{ih}$ - балаларга өстәмә белем бирү учреждениесенең тышкы зурлыгы, куб. метр;

$So_i$ - балаларга өстәмә белем бирү учреждениесенең гомуми мәйданы, куб. метр;

$q_0$ - балаларга өстәмә белем бирү учреждениесенең температура -30 град.С булганда бинаны җылытуның чагыштырма характеристикасы, 5 нче таблица нигезендә кабул ителгәнчә;

16 - норматив хокукый актлар таләпләренә туры килә торган эчке һава температурасы, град. С;

$t_{med}$ - җылыту чорына тышкы һава температурасы (СНиП буенча Татарстан Республикасы климат шартларына 5,7 град. С туры килә), град. С;

$10^{-6}$ - ккал ны Гкал га күчерү коэффициенты;

T - җылыту чорында җылыту системасының эшләү дәвамлылыгы (бердәй нормага китерелгән исәп-хисап өчен барлык торак пунктлар өчен 218 тәүлек кабул ителә);

24 - җылыту системасының бер тәүлеккә эш сәгатьләре саны;

$T_{iq}$ - законнар нигезендә билгеләнгән җылылык энергиясе тарифы, Гкал.

5 нче таблица

Балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләре биналарын җылытуның чагыштырма характеристикалары

| т/с № | Тышкы яктан бинаның зурлыгы, куб. метр | Бинаны җылытуның чагыштырма характеристикасы, ккал/(куб. метр x ч x град. С) |
|---|---|---|
| 1 | 5000 гә кадәр | 0,39 |
| 2 | 5001 - 10000 | 0,35 |
| 3 | 10000 нән артык | 0,33 |

44. Салкын су белән тәэмин итү, кайнар су белән тәэмин итү, су бүлү, электр белән тәэмин итү, каты көнкүреш калдыкларын чыгару һәм утильләштерү өчен түләүнең төзәтелә торган күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$P_i^{cw,hw,can,el,lit} = N^{cw,hw,can,el,lit} \times T_i^{cw,hw,can,el,lit},$$

монда:

$T_i^{cw,hw,can,el,lit}$ - законнар нигезендә билгеләнгән салкын су белән тәэмин итү, кайнар су белән тәэмин итү, су бүлү, электр белән тәэмин итү, каты көнкүреш калдыкларын чыгару һәм утильләштерү тарифлары. Балаларга өстәмә белем бирү учреждениесенең коммуналь хезмәт белән тәэмин ителеше булмаган очракта коммуналь хезмәткә тариф күләме нольгә тигез була.

45. Биналарны һәм корылмаларны агымдагы карап тоту һәм ремонтлау өчен түләүнең төзәтелә торган, бер укучыга фактта мәйдан белән тәэмин ителүне исәпкә алучы зурлыгы түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

:

$$S_i = S_{q_i} \times T_{hs}.$$

Биналарны һәм корылмаларны агымдагы карап тоту һәм ремонтлау өчен түләүнең төзәтелә торган зурлыгын исәпләгәндә бер укучыга фактта мәйдан белән тәэмин ителү кулланыла, әгәр дә бер укучыга фактта мәйдан белән тәэмин ителү, әлеге нигезләмәнең 26 пункты нигезендә, бер укучыга норматив буенча мәйдан белән тәэмин ителүдән артмаса.

Башка очракларда әлеге күрсәткечне исәпләгәндә бер укучыга фактта мәйдан белән тәэмин ителү күрсәткече булып, әлеге нигезләмәнең 26 пункты нигезендә, бер укучыга норматив буенча мәйдан белән тәэмин ителү кабул ителә.

46. Биналарны һәм корылмаларны капиталь ремонтлау өчен түләүнең төзәтелә торган, бер укучыга фактта мәйдан белән тәэмин ителүне исәпкә алучы зурлыгы түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$B_i = S_{q_i} \times C_{bd} \times N_{cr} \times k_{b_{min}} .$$

Биналарны һәм корылмаларны капиталь ремонтлау өчен түләүнең төзәтелә торган зурлыгын исәпләгәндә бер укучыга фактта мәйдан белән тәэмин ителү кулланыла, әгәр дә бер укучыга фактта мәйдан белән тәэмин ителү, әлеге нигезләмәнең 26 пункты нигезендә, бер укучыга норматив буенча мәйдан белән тәэмин ителүдән артмаса. Башка очракларда әлеге күрсәткечне исәпләгәндә бер укучыга фактта мәйдан белән тәэмин ителү күрсәткече булып, әлеге нигезләмәнең 26 пункты нигезендә, бер укучыга норматив буенча мәйдан белән тәэмин ителү кабул ителә.

47. Балаларга өстәмә белем бирү учреждениесендә уку процессын оештыру өчен таләп ителә торган мөлкәт салым салу объекты дип таныла торган салым чигерүләре зурлыгы, шул исәптән җир салымнары, законнар нигезендә гамәлдәге салым ставкалары буенча исәпләнә торган факттагы салым буенча өстәлгән суммага туры килә.

## 4 бүлек. Балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен финанс белән тәэмин итү күләмен исәпләү тәртибе

48. Балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениесен финанс белән тәэмин итү күләме үз эченә түбәндәгеләрне ала:

1) балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрендә өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруны финанс белән тәэмин итү күләме;

2) балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениесенең мөлкәтен карап тотуны финанс белән тәэмин итү күләме.

49. Балаларга өстәмә белем бирү мәгариф учреждениесен финанс белән тәэмин итү күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$FOYDOH_i^t = \sum_{d=1}^{k} \sum_{p=1}^{j} \sum_{s=1}^{n} N_{spd}^t \times m_{i_{spd}} \times K_{pp} + BNSI \times KNSI \times SO_i ,$$

монда:

$m_{i_{spd}}$ - сәнгать-эстетика юнәлешендә балаларга өстәмә белем бирү мәгариф

учреждениесендә укучылар саны;

n – балаларга өстәмә белем бирү программасы юнәлешләре саны;

j – укыту дәрәҗәләре саны;

к – укыту сроклары саны;

К - финанслау нормативларына төзәтмәләр коэффициенты рр күчү чорына. Күчү чорына финанслау нормативларына төзәтмәләр коэффициенты оптимальләштерү үткәрү чорына балаларга өстәмә белем бирү хезмәтләре күрсәтүгә фактта барлыкка килгән бюджет чыгымнары күләмен саклауны тәэмин итә. План чорына төзәтмәләр коэффициенты балаларга өстәмә белем бирү хезмәтләре күрсәтүне тәэмин итүгә фактtагы бюджет чыгымнарының план чорына норматив чыгымнарга мөнәсәбәте буларак билгеләнә.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова